| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

27 декабря 2021г. С.Федоровское № 35

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Федоровский авыл җирлеге Советының кайбер
карарларын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федорвский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында нигезләмә хакында» 2011 елның 16 декабрендәге 5 номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Советының «Федоровский авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 10 июнендәге 17 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Зайнуллин